ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 498-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Прокуроры тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» 498-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе

БЕРКЕТМӘ
БҮЛЕГЕ
ПРОТОКОЛЬНЫЙ
ОТДЕЛ

Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2023 елның 18 декабре
№ 2295-VI ДС

проект

Татарстан Республикасы
прокуроры тарафыннан
кертелә

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында**

**1 статья**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» 2010 елның 14 октябрендәге 71-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 4 статьясындагы 1 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 10 (II өлеш); 2011, № 10; 2013, № 10; 2015, № 10 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнары җыентыгы, 2022, № 83 (I өлеш), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«1. Юридик затларның яисә юридик зат төземичә генә эшкуарлык эшчәнлеген башкаручы гражданнарның түбәндәге объектларда (территорияләрдә, урыннарда), тәүлекнең нинди вакыты булуга карамастан, балигъ булмаганнарга булу тыела:

1) бары тик сексуаль характердагы товарлар реализацияләү өчен билгеләнә торган объектларда (территорияләрдә, урыннарда);

2) сыра рестораннарында, шәрәб барларында, сыра барларында, чәркәханәләрдә, бары тик алкоголь продукциясен реализацияләү өчен генә билгеләнгән башка урыннарда;

3) кальяннар кулланып хезмәт күрсәтелә торган урыннарда, шулай ук милек хуҗасы яки милек хуҗасы вәкаләт биргән башка зат карары нигезендә тәмәке тарту, никотинлы продукция куллану яки кальяннар куллану рөхсәт ителә торган махсус билгеләнгән изоляцияләнгән урыннарда.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми рәвештә басылып чыккан көннән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Рәисе

**«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектына**

**АҢЛАТМА**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проекты балалар һәм яшүсмерләр тарафыннан тәмәке һәм никотинлы продукция куллануны популярлаштыруны булдырмауга юнәлдерелгән.

Балигъ булмаганнарның кальяннар кулланып хезмәт күрсәтелә торган биналарда, шулай ук тәмәке тарту, никотинлы продукция куллану яки кальян куллану рөхсәт ителгән махсуслаштырылган бүлмәләрдә булулары аларның тәмәке һәм никотинлы продукция куллануның зарарлы моделен проекцияләүләрен һәм үзләрендә куллануларын кире кага алмый, бу аларның әлеге урыннарда булуыннан икенчел тәмәке төтененең тәэсире кебек үк, аларның сәламәтлегенә һәм физик үсешләренә тискәре йогынты ясый.

Шулай итеп, федераль законнарда балигъ булмаган затка яки балигъ булмаганнарга тәмәке продукциясен, никотинлы продукцияне, кальяннарны һәм никотинлы продукцияне куллану өчен җайланмаларны сату тыелса да, балигъ булмаганнарга тәмәке куллану яки никотинлы продукцияне куллану тыелса да, республикада ел саен яшүсмерләр тарафыннан тәмәке һәм никотинлы продукция куллану фактлары теркәлә.

2021 елда федераль закон нигезендә билгеләнгән тәмәке тартуны, никотинлы продукция куллануны яки аерым территорияләрдә, биналарда һәм объектларда кальяннарны куллануны тыюны бозган өчен Россия Федерациясе Административ хокук бозулар кодексының 6.24 статьясы буенча - 30, 2022 елда – 30, агымдагы елның беренче яртыеллыгында – 11 балигъ булмаган бала җаваплылыкка тартылган. Әлеге проблема республиканың эре шәһәрләренә генә (Казан, Чаллы, Әлмәт) хас булып калмыйча, каралган хокук бозулар Чирмешән, Алабуга, Лениногорск, Арча, Кукмара һәм республиканың башка районнарында да теркәлгән.

Гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендә кеше һәм граждан хокукларын тирә-юньдәге тәмәке төтененнән, Россия Федерациясе субъектлары территорияләрендә тәмәке куллану яки никотинлы продукция куллану нәтиҗәләреннән яклау, шул исәптән «Гражданнарның сәламәтлеген тирә-юньдәге тәмәке төтененнән, тәмәке куллану нәтиҗәләреннән яки никотинлы продукция кулланудан саклау турында» 2013 елның 23 февралендәге 15-ФЗ номерлы Федераль законның 6 статьясы нигезендә әлеге хокукларны яклауга өстәмә чаралар күрү Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләренә карый.

Балаларны икенчел тәмәке төтененнән саклау, шулай ук яшүсмерләр арасында тәмәке тартуны профилактикалауның өстәмә чарасы буларак, закон проекты белән балигъ булмаганнарны кальяннар кулланып хезмәт күрсәтелә торган биналарда, шулай ук милек хуҗасы яки милек хуҗасы вәкаләт биргән башка зат карары нигезендә тәмәке тарту, никотинлы продукция куллану яки кальяннар куллану рөхсәт ителә торган махсус билгеләнгән изоляцияләнгән биналарда балигъ булмаганнарга булуны тыю кертү тәкъдим ителә.

Закон проекты нигезләмәләре 2025 елга кадәрге чорга Россия Федерациясенең демографик сәясәте концепциясендә каралган төп бурычларны үтәүгә туры килә (халыкның гомер озынлыгын арттыру, туучылар санын арттыру, халыкның сәламәтлеген саклау һәм ныгыту, сәламәт яшәү рәвешен алып бару өчен шартлар тудыру һәм мотивация формалаштыру).

**«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалткан дип танылырга, туктатылып торырга, үзгәрешләр кертелергә яки кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы закон проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасында балаларның сәламәтлегенә, аларның физик, интеллектуаль, психик, рухи һәм әхлакый үсешенә зыян китерүне кисәтү чаралары турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына үзгәреш кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә чыгымнар таләп итми.